ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

26.01.2022 — 07

пос. Октябрьский

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегендә 2022 елга җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Җирләү һәм җирләү эше турында» 12.01.1996 ел, № 8-ФЗ Федераль законның 9 статьясындагы 3 пункты һәм 12 статьясындагы 3 пункты нигезендә, «2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәте карары проекты буенча, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 18.05.2007 ел, №196 һәм «Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты мәсьәләләре» 15.06.2010 ел, № 468 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Октябрьский авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә 6964 сум 68 тиен күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1,2 кушымталар нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук Октябрьский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы — Ш. Р. Азизов

Татарстан Республикасы Югары Ослан
муниципаль районы Октябрьский авыл
җирлеге Башкарма комитетының
26.01.2022 ел 7 карарына
1 нче номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегендә 2022нче елның 1нче февраленнән күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү | 3601,25 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (гәүдә калдыкларын) зиратка озату | 1116,65 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2246,78 |
| Барлыгы | 6964,68 |

Татарстан Республикасы Югары Ослан
муниципаль районы Октябрьский авыл
җирлеге Башкарма комитетының
26.01.2022 ел 7 карарына
2 нче номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегендә 2022нче елның 1нче февраленнән күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
| --- | --- |
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Мәетне кәфенләү | 666,35 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле әйберләрне бирү һәм китерү | 2934,90 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (гәүдә калдыкларын) зиратка илтү | 1116,65 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2246,78 |
| Барлыгы | 6964,68 |